Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советының чираттан тыш утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

1 сентябрь, 2020 ел № 76

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлегеннән авыл җирлеге мөлкәте объектлары реестрын, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районына тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлегеннән авыл җирлеге мөлкәте объектлары реестрын, шулай ук кече һәм урта эшкуарлык субъектларына бирү өчен билгеләнгән мөлкәт исемлеген Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгару вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районына тапшырырга.
2. Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шигали авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы бюджетына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар исәбенә тәэмин ителә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткергәннән) соң үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Шигали авыл җирлеге башлыгы
вазыйфасын вакытлыча башкаручы О.В. Маркова

СОВЕТ ШИГАЛЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ